| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **Постановление** | | **Карар** |
|---|---|---|
| 09.11.2018 | Казан ш. | № 10-30/кс |

2018 елга «Октябрь инженерлык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Октябрь инженерлык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Октябрь инженерлык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәиснең беренче урынбасары А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
2018 елның 9 ноябрендәге 10-31/кс
номерлы карары
2018 елның 9 ноябрендәге 10-30/кс
номерлы карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Октябрь инженерлык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | |
| 1. | «Октябрь инженерлык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | |
| 1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 31,73 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | 26,89 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге